
М.Мәһдиев «Без - 41 нче ел балалары».

Укытучы, язучы , галим М.Мәһдиев 1930 нчы елның
1 нче декабрендә Арча районы Гөберчәк авылында туа.

Сиректән авылы мәктәбендә, аннан Арча педагогия училищесында укый.



# КИТАПЛАРЫ :

- Без 41 нче ел балалары.
- Солдатлар.
- Кеше китә , җыры кала.
- Бәхилләшү.

# ТЕМАЛАРЫ :

- Авыл тормышы.
- Мәхәббәт.
- Сугыш. Дезертирлык.
- Колхозлашу.
- Хатын – кыз батырлыгы.

1.

# «Без 41 нче ел балалары» әсәренә А.Г.Яхин методологиясе нигезендә анализ :

Темасы : сугыш елларында тылдагы тормыш вакыйгалары .

Проблемасы : яшүсмерләрнең үсеш чоры , дөньяга күзләре ачыла баруы .

Идеясе : авыр сугыш елларында да , балаларның тырышып – тырмашып белем алу теләге.

**2**. Бу әсәр үрнәк программада дөрес урын алган. Аның дәреслеккә кертерлек кыйммәте бар.Мавыгып укыла торган бу җыйнак повестьны җиргә сибелгән бер уч энҗе белән чагыштырасы килә. Әсәр берсеннән – берсе кызыклы эпизодлары , бик тә үзенчәлекле геройлары белән хәтергә сеңеп кала , бик эчтәлекле , вакыйгаларга бик бай. Күтәрелгән проблемалары бүгенге көндә дә бик актуаль , чөнки төп тема – авыр сугыш елларында тылдагы тормыш вакыйгалары.

3. Бу әсәр татар төркемнәрендә , 7 нче сыйныфларда өйрәнелә һәм бу дөрес тә. Әсәр кызыклы булуына карамастан , рус төркемнәрендә укучы балалар өчен бу әсәр авыррак бирелер иде кебек. «Без – 41 ел балалары»н укыган һәрбер өлкән сыйныф укучысы үзен әсәрдәге яшьтәшләре белән һәм авыр сугыш еллары белән хәзерге рәхәт тормышны чагыштыра ала. Бу повесть аларга бу яктан үрнәк булырлык! «Без – 41нче ел балалары» әсәре хәзерге яшьләрне бүгенге рәхәт тормышның кадерен белергә өйрәтә.